КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 24 сентябрь г.Казань № 822

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 25 май, 368 нче карары белән расланган Халык сәнгать һөнәрләре тармагында «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм физик затларга булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык сәнгать һөнәрләре тармагында «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм физик затларга булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 25 май, 368 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 июль, 516 нчы; 2016 ел, 7 октябрь, 720 нче; 2017 ел, 25 май, 299 нчы; 2020 ел, 18 июль, 605 нче; 2021 ел, 31 май, 424 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1044 нче; 2023 ел, 1 март, 193 нче; 2023 ел, 17 июль, 849 нчы, 2023 ел, 28 август, 1027 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм физик затларга булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибенә, 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1.1. Әлеге Тәртип «Халык сәнгать һөнәрләре турында» 1999 елның 6 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль

законнар (алга таба - 209-ФЗ номерлы Федераль закон), «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы, «Халык сәнгать һөнәрләре турында» 2024 елның 18 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә халык сәнгать һөнәрләре тармагында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин